КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 25 декабрь

г.Казань

№ 1201

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының стандартлары турында» 2009 ел, 30 июнь, 445 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының стандартлары турында» 2009 ел, 30 июнь, 445 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 19 июнь, 525 нче; 2015 ел, 12 сентябрь, 666 нчы; 2017 ел, 21 март, 162 нче; 2017 ел, 13 июль, 490 нчы; 2018 ел, 13 декабрь, 1128 нче; 2023 ел, 5 сентябрь, 1076 нчы; 2024 ел, 25 апрель, 276 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 2 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына, Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына, Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясенә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан

Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә, үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:».

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына, Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына, Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясенә, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә, 2025 елның 1 июленә кадәр Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының стандартларын раслау, билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының гамәлдәге стандартларына үзгәрешләр кертү буенча эшләрне төгәлләргә һәм тиешле норматив хокукый актлар проектларын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин